РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
КРЯШ-ШУРАНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЕРЭШ-ШУРАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423978, Р.Т. Муслюмовский район, с. Кряш-Шуран, ул. Центральная 6а,
Kshur.Mus@tatar.ru тел. (8-85556) 3-35-45
ИНН 1629003978, КПП 162901001, ОГРН 1061687005203, ОКАТО 92242825000,
ОКТМО 92642425

---

# К А Р А Р № 9

Керэш-Шуран авылы "17" апрель 2021 ел.

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Керэш-Шуран» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Төп муниципаль актка үзгәрешләр кертә торган муниципаль акттагы хаталарны төзәтү зарурлыгына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 27.02 нен 3 номерлы карары белән расланган (2021 елның 22 феврале, 2021 елның 04 марты ред.) Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Керэш-Шуран авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. 10 пунктның икенче җөмләсен икенче абзац дип санарга һәм аны түбәндәге редакциядә бирергә:**

«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы « Керэш-Шуран авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына шартнамә (алга таба – урнаштыруга шартнамә) Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Башкарма комитеты (алга таба – авыл җирлеге Башкарма комитеты) һәм хуҗалык итүче субъект (шәхси эшмәкәр яисә юридик зат, әгәр законнарда башкалар каралмаган очракта) арасында әлеге Тәртиптә билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә, законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурыч булмау турында мәҗбүри рәвештә белешмә булган очракта төзелә.»

**1.2. 10 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:**

«Мөрәҗәгать итүче тарафыннан 10 пунктның 2 абзацында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Керэш-Шуран авыл җирлеге Башкарма комитеты ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә Россия Федераль салым хезмәтеннән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмәләр соратып ала».

**1.3. 20 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:**

«20. Сатуларсыз урнаштыруга шартнамә төзүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

1) әлеге Тәртипнең 19 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

2) хуҗалык итүче субъект тарафыннан дөрес булмаган белешмәләре булган гариза бирү;

3) әлеге Тәртипнең 19 пункты таләпләренә туры килгән элек бирелгән гаризаның булуы.

4) законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурыч булу.»

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru)

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе :** **Р.Г.сафиуллин**